СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение　　　　　　　　　　　　　　　　　　Карар

№ 1-52　　　　　　　　　　　　　　　　　　“ 22” июнь 2020 ел

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советына депутатлар сайлау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясының 1, 2 өлеше, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3,6,7 пунктлары, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2, 4 өлеше, 105 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советына дүртенче чакырылыш депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. . Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында (http://mamadysh.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), «Нократ» («Вятка») район газетасында бастырып чыгарып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка игълан итәргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге Советы рәисе　　　　　　　　/Р.К.Хафизов/

СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ